ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 15.08.2024 **КАРАР** № 109

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм аларны шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 20 номерлы карары (19.09.2018 № 105, 10.02.2022 № 11, 21.11.2023 № 208 карарлар редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы Советы аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм аларны шәхсән кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10.15 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«10.15. Органнарда чираттан тыш шәхси кабул ителү хокукына гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм шундый балаларны озатып йөрүче затлар ия.»

1.2. 6.21 пунктны «, электрон почта адресларына яисә Бердәм порталда шәхси кабинетлар адресларына» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Р.Ф. Хисамәтдинов